| ГЛАВА Иж-Бобьинского сельского поселения Агрызского муниципального района Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 с. Иж-Бобья № 01

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Иж-Бубый авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башлыгы **к а р а р и т т е:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубыйторак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын 2022 елның 27 октябрендә 15 сәг 00 мин билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубыйторак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын 2022 елның 27 октябрендә 17 сәг 00 мин билгеләргә.
3. Халык исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга:

-1 этап: Иж-Бубый авылының 1- Колхоз тыкрыгы, 2- Колхоз тыкрыгы, Заречная, Колхоз, Лесная, Яшьләр, Татарстан, Татарстан тыкрыгы, Хезмәт урамында яшәүчеләр.

- 2 этап: Иж-Бубый авылының Ижау, Магистральная, Набережная, Яңа, Үзәк урамында яшәүчеләр.

– Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бубый торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге

формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, ирекләреннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыены кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Иж-Бобья авылына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- Иж-Бобья авылы урамнарын кардан чистарту;
- Тракторны ремонтлау һәм тоту;
- Мотобур алу;
- Триммер алу;
- Видеокүзәтү системасын урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иж-Бубый авылы, Үзәк ур., 20, авыл мәдәният йорты бинасына үткәрергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иж-Бубый авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р. ВАҺАПОВ

АГРЫЗСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Совет Иж-Бобьинского сельского поселения
Иж-Бубый авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002480
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ